**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«30» ноябрь, 2023 ел

№ 904

2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә атчылыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 мартындагы 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, «2013 - 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында» РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән аерым юнәлешләр буенча АПКга дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 елның 31 маендагы 397 номерлы карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Питрәч муниципаль районы территориясендә кече хуҗалыкларны (ЛПХ һәм КФХ) үстерүгә муниципаль ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә атчылыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 16 мартындагы 191 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә үз йогынтысында кагыла ".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән (http://www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Д. Сабитовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин